**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020 № 152

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең "Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен Кама Тамагы территорияләренә беркетү турында" 2020 елның 10 гыйнварындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлеше, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында» 2014 елның 22 гыйнварындагы 32 номерлы боерыгы, шулай ук Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «2020 елда мәгариф оешмаларына кабул итү тәртибе турында» 2020 елның 3 февралендәге в-159/04 номерлы хаты нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен Кама Тамагы территорияләренә беркетү турында» 2020 елның 10 гыйнварындагы 5 номерлы карарына 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 3. | "Советлар Союзы Герое Чирков Михаил Алексеевич исемендәге Кама Тамагы кадет интернат-мәктәбе» ДБГБУ | штп Куйбышев Затоны |

2. 2 пунктка үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кама Тамагы муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә муниципаль районның гомуми белем бирү оешмаларына беркетелгән территорияләрендә яшәүче төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында укырга тиешле балаларны исәпкә алуны, шулай ук бертуганнары - абый һәм (яки) апалары белем алган муниципаль белем бирү оешмаларына гомуми башлангыч белем бирү программалары буенча укуга өстенлекле кабул итү хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтларында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ, шулай ук районның гомуми белем бирү оешмаларының рәсми сайтларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В.Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин